**Республика Татарстан**

**Сармановский муниципальный район Карашай Сакловское сельское поселение**

**423378 ул.Ленина д.100 с.Карашай Саклово Телефон: 885559 4-92-18**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай Саклау авыл жирлеге**

**423378 ,Карашай Саклау авылы, Ленин ур.100 йорты Телефон: 885559 4-92-18**

РЕШЕНИЕ КАРАР
25 июнь 2024 ел № 92

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычн
ы түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә ниге
зләрен билгеләү турында.

«Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сарман муниципаль районының «Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә.

- варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

- Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документла түбәндәгеләр:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Сарман муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы

Сарман муниципаль район
Карашай-Саклау авыл җирлеге
Совет рәисе В.В.Хосниева